Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Советы

**КАРАР №IV-5**

Балык Бистәсе штп. 2025елның 22 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2014 елның 13 декабрендәге XLII-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы Нигезләмәне «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2014 елның 13 декабрендәге XLII-3 номерлы карары ( 26.09.2023 № XLII-8редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Нигезләмәнең 4 статьясындагы 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Контроль-хисап палатасы рәисе вәкаләтләренең срогы биш ел тәшкил итә.».

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы Башлыгы Р.Р. Ислямов